КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1270

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 7 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 7 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июль, 466 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт

вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 нче пунктта:

икенче абзацта «һөнәри» сүзен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «һөнәри» сүзен төшереп калдырырга;

2.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медицина-санитария өлеше поликлиникасында Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны, шулай ук аларның гаилә әгъзаларын (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) теркәү Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затның мәҗбүри медицина иминияте полисы һәм хезмәт таныклыгы яисә, пенсиягә чыккан очракта, аның хезмәт кенәгәсе (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты тарафыннан расланган өземтәсе) һәм (яки) тиешле рәвештә расланган кәгазь чыганактагы яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендәге хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2.2 нче пунктта «һөнәри» сүзен төшереп калдырырга.

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин